СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 385

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, рәис урынбасарының, контроль-хисап органының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, рәис урынбасарының, контроль-хисап органының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карарына белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1. пунктының 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи окладлы күләменә кабатлы исәпләнә, ул 13 990 сум тәшкил итә.».

1.2. Нигезләмәнең1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затларының, Алабуга муниципаль районындагы контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының акчалата түләү күләмнәре

| Вазифаның атамасы | Айлык акчалата түләү, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 38 889 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 34 998 |
| Депутат | 18 848 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16 019 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 34 998 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 31 475» |

1. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. 3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә..

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов